**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2017-2018 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

## I. Теоретик биремнәр (35 балл).

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең төрен һәм жанрын билгеләгез (20 балл):

*“Идегәй”;*
*М.Әгъләмов “Җил дә җил”;*
*Г.Бәширов “Туган ягым – яшел бишек”;*
*Г.Камал “Беренче театр”;*
*Ф.Кәрим “Сибәли дә сибәли”.*

3. Әлеге билгеләмәләрдән пейзаж төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (7 балл):

*1) әсәрләрдә табигать күренешләренең бирелешен ачыклый торган теоретик төшенчә;*
*2) геройның тышкы кыяфәтенең бирелеше;*
*3) әсәрдә табигать образлары ярдәмендә геройның күңел кичерешләрен тасвирлау;*
*4) әсәрдәге вакыйгаларның бара торган урынын сурәтләү.*

4. М.Әгъләмовның “Җил дә җил” шигырендә җил образы кайсы теоретик төшенчәгә туры килә (8 балл):

*А) юллар җыры;*
*Б) Символ;*
*В) Пейзаж;*
*Г) метафора.*

## II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).

1. Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәрендә Әлмәндәр белән Әҗәл тартышы ничек тәмамлана? (5 балл)
2. Әлмәндәр “*син дә берүзең чишмәгә килгәнсең ич. Төн дип тормагансың*”, – дип, кемгә мөрәҗәгать итә? (10 балл)
3. “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәрендә Т.Миңнуллин Әлмәндәр һәм Әҗәл образлары ярдәмендә нинди мәңгелек төшенчәләр турында сөйли? Үз фикерегезне дәлилләп бирегез (15 балл)
4. Ни өчен әсәр бүген дә актуальлеген югалтмаган дип уйлыйсыз? (15 балл)

## III. Иҗади бирем (20 балл).

1. Күңел матурлыгы турында кечкенә генә хикәя языгыз.